РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** Буа шәһәре **КАРАР**

18 август 2026 ел № 2-18

2026 елга Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районының муниципаль милекне хосусыйлаштыруның
фаразлау планына (программасына) үзгәрешләр
кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон (06.03.2019 елгы редакция), Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2012 елның 29 декабрендәге 3-40 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2025 елның 20 декабрендәге 3-6 номерлы карары белән расланган «2026 елга Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлеге муниципаль милеген хосусыйлаштыруның фаразлау планына (программасына)» үзгәрешләр кертергә.
2. Карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында һәм Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы башлыгы урынбасары И.Ф,Еремеевка йөкләргә.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Совет рәисе Р.Р. Камартдинов

Буа муниципаль районы Советының

2026 елның 18 августындагы 2-18 номерлы
карарына кушымта

**2026 елга Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының муниципаль милеген хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) (өстәмә мөлкәт)**

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. 2026 елга Буа муниципаль районының муниципаль милеген хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) (алга таба - Фаразлау планы) Татарстан Республикасы Буа район Советының 2012 елның 29 декабрендәге 3-40 номерлы карары белән расланган «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» Федераль закон, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Уставы, «Буа муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында» нигезләмә нигезендә эшләнде.

**2. Хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль мөлкәт**

2026 елда ачык аукцион сәүдәләрендә сатылырга тиешле күчемле мөлкәт

| № т/б | Объект исеме | Объектның адресы, урнашу урыны/ характеристикасы | Гамәлгә ашыруның планлаштырылган вакыты/ гамәлгә ашыру ысулы |
|---|---|---|---|
| 1 | Торак булмаган бина театр | ТР, Буа шәһәре, К.Маркс урамы, 68 й., кад.номеры 16:14:990143:191 | 2026 ел, *аукционда сату юлы белән сату, гавами тәкъдим ярдәмендә сату, бәясен игълан итмичә сату |
| 2 | Торак булмаган бина котельная | ТР, Буа шәһәре, К.Маркс урамы, 68 йкад.номеры 16:14:990143:190 | 2026 ел, *аукционда сату юлы белән сату, гавами тәкъдим ярдәмендә сату, бәясен игълан итмичә сату |
| 3 | ТС 222335 | дәүләт номеры С 482 АК, 2013 чыккан елы | 2026 ел, *аукционда сату юлы белән сату, гавами тәкъдим ярдәмендә сату, бәясен игълан итмичә сату |

*Сатуның һәр чираттагы ысулы алдагы ысул булмаганнан соң гамәлгә ашырыла, сатулар электрон формада үткәрелә.

3. Вәкаләтле зат турында

3.1. «ТР Буа муниципаль районы муниципаль берәмлегенең мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ (сатуларны оештыручы) Буа муниципаль районының муниципаль мөлкәтен сату, сату-алу шартнамәсе төзү, тапшыру актына билгеләнгән тәртиптә кул кую буенча торглар үткәрүгә вәкаләтле зат булып тора.